ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.08.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2086**

Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ буларак тану тәртибен раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруда алдагы чаралар һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камиллләштерү хакында» 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ буларак тану тәртибен кушымтада каралганча яңа редакциядә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 25 октябрендәге «Зеленодольск шәһәрендә гражданнарны социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ буларак тану тәртибен һәм Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең квоталарын куллануга хокукны тану тәртибен» 1507 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтына (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 елның
10 августындагы 2086 номерлы
карарына кушымта

**Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ буларак тану ТӘРТИБЕ**

1. Гражданнарны Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ буларак тану тәртибе (алга таба - Тәртип) Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ буларак гражданнарны (гаиләләрне) тану хокукын һәм шартларын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге терминнар, билгеләмәләр һәм кыскартулар кулланыла:

- иҗтимагый торак комиссиясе - Зеленодольск муниципаль районында социаль ипотека буенча торак урыннар сатып алу өчен гаиләләрне исәпкә алу буенча иҗтимагый торак комиссиясе;

- Дәүләт торак фонды - «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган оешма.

3. Социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ буларак түбәндәге категория гражданнар (гаиләләр) танылырга мөмкин:

3.1. Янгын, йорт ишелү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр, шулай ук билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак бинада яшәүче гражданнар (гаиләләр);

3.2. Инвалидлар, инвалид балалары булган гаиләләр;

3.3. Сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт инвалидлары, һәлак булган (вафат булган) сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт инвалидлары;

3.4. күпбалалы гаиләләр;

3.5. дини оешмалар хезмәткәрләре;

3.6. Авыр тормыш хәленә тарыган, шуның нәтиҗәсендә тораксыз калган һәм хәзерге вакытта вакытлыча торак бинасында яшәүче гражданнар;

3.7. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбендә торучы гражданнар (гаиләләр); 2005 елның 1 мартына кадәр торак урыннарына мохтаҗлар буларак яшәү урыны буенча исәпкә алынган гражданнар; Муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча бирүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар, Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән гражданнардан тыш.

4. Социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип тану өчен гражданнарның (гаиләләрнең) гаризаларын карау түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

4.1 әлеге Тәртипнең 3.1 - 3.7 пунктларында күрсәтелгән категорияләргә караган гражданнар (гаиләләр), социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар исәбенә басарга теләүчеләр Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба-Башкарма комитет) язсә

Зеленодольск муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә (алга таба-КФҮ) Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итәләр.

4.2 Аннары гражданин (гаилә) шәхсән 1 нче кушымта нигезендә Башкарма комитетка мөрәҗәгать итә. Әгәр граждан (гаилә) әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән категориягә керә икән, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге "Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында" 190 номерлы карары (алга таба ТР МК 15.04.2005 №190 карары) белән расланган Мөрәҗәгать итүчене һәм аның гаиләсен социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар исемлегенең 2 пунктында күрсәтелгән документларны (алга таба исемлек)өстәмә рәвештә тапшыра. Әгәр граждан (гаилә) ташламаларга ия булса, исемлекнең 3 пунктында күрсәтелгән документларны өстәмә рәвештә тапшыра.

4.3. Башкарма комитетка гражданны (гаиләне) социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану турында гариза кергәч , гариза иҗтимагый торак комиссиясе тарафыннан карау өчен исәпкә кую эше материалларына теркәлә.

5. Иҗтимагый торак комиссиясе утырышы йомгаклары буенча социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип тануга гражданнарның (гаиләләрнең) җыелма исемлеге (алга таба-җыелма исемлек) төзелә (2 нче кушымта).

5.1 Алга таба ТР Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карарының 15 п., «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруда алдагы чаралар һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү хакында» 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының (алга таба ТР МК 02.08.2007ел №366 карары) 1.6 п.таләпләре нигезендә җыелма исемлек Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы раславына (алга таба - Совет) бирелә.

5.2 Совет раслаганнан соң, җыелма исемлек Башкарма комитет тарафыннан ТР МК 02.08.2007ел №366 карары нигезендә, кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнар реестрына кертү өчен, Дәүләт торак фондына җибәрелә.

6. Кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип танылган гражданнар (гаиләләр) исемлегеннән төшереп калдыру нигезләре:

- кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип танылган гражданнар (гаиләләр) исемлегеннән төшереп калдыру турында граждан тарафыннан гариза бирү;

- кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнар өчен квотага кертелгәнгә кадәр фатир сайлаган булу;

- әлеге Тәртипнең 3.1 - 3.7 пунктларында күрсәтелгән гражданнар (гаиләләр) категорияләренә кертү өчен нигезләрне югалту;

- ТР МК15.04.2005 №190 карарының 18 п пунктында күрсәтелгән нигезләрдә учеттан төшерелгән.

Зеленодольск муниципаль
районында  гражданнарны социаль
ипотека буенча торак урыннары
алуда кичектергесез  ярдәмгә мохтаҗ
буларак тану тәртибенә
1нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенә

___________________________________

________________________________

___________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)
түбәндәге адрес буенча яшәүче:

___________________________________

___________________________________
(почта адресы тулысынча)

___________________________________
(элемтә өчен телефоны)

Гариза

Мине (минем гаиләмне) социаль ипотека буенча торак алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗлар дип гражданнарны тану тәртибе һәм шартларының ___пункты нигезендә, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуда кичектергесез ярдәмдә мохтаҗ дип тануыгызны сорыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл белешмәләрне үз эченә ала.

| | |
|---|---|
| ______________________________ | ______________________________ |
| (дата) | ( имза) |

Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны социаль ипотека буенча торак урыннары алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ буларак тану тәртибенә

2 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче, 20_____ елга кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ булган гражданнар исемлеге**

| № т/б | Мөрәҗәгать итүче Ф.И.А.и. | Эш урыны | Ташламалар категориясе | Исәпкә куелганда гаилә составы | Яшәү (теркәү) урыны адресы | Таләп ителгән торак төре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |